| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО - КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

№ ____1767/о______

П Р И К А З

Б О Е Р Ы К

«__08___»_____12_______2025

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 04.06.2012 ел, № 198 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Рәсәй Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 19-21 статьялары, “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы һәм “Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында” 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының” Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында” 11.09.2025 ел, № 1303/о боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 17.11.2025 ел, № 10-53/14022 бәяләмәсен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының “Зәй муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында” 04.06.2012 ел, № 198 карары белән расланган (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының, 19.12.2018 № 364, 23.11.2020 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына әлеге боерыкка кушымта нигезендә җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасын яңа

редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсенең Кама агломерациясен үстерү бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручыга (Ч. З. Рәхмәтуллина) тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрү;

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыру;

әлеге боерыкны “Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

әлеге боерыкны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча урнаштыру.

3. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны территорияләрне үстерү департаментының агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А. Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н. Кудряшев

Отдел контроля исполнения документов

Приложение
к приказу Министерства
строительства, архитектуры
и жилищно-коммунального
хозяйства Республики Татарстан
от 08.12.21 № 1167/о

# СХЕМА ТЕРРИТОРИАЛЬНОГО ПЛАНИРОВАНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## *Карта планируемого размещения объектов местного значения*

